ГЛАВА
ЗВЕЗДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗВЕЗДА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Хорновар-Шигали авылы

2021 елның 18 ноябре № 17

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Звезда авыл җирлегенең Яңа Шигали торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Звезда авыл җирлеге Уставының 12.1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Звезда авыл җирлеге Советының 11.10.2019 ел, №53/1 карары (2019елның 15 ноябрендәге 55/6 редакөиясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Чупрәле мунниөипалҗ районы Звезда авыл җирлеге торак пунктларында гранданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәсе нигезендә КАРАР ИТӘМ:

1.Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Звезда авыл җирлегенең Яңа Шигали торак пунктында 2021 елның 2 декабренә 15:00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Яңа Шигали авылы, Школьная урамы, 2 нче йорт, Яңа Шигали авыл клубы адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«2022 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Шигали авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 300 сум күләмендә акча кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Чапаев урамы буенча Яңа Шигали авылына вак таш җәю;

- Дзержинский урамыннан Калинин урамында Яңа Шигали авылындагы күперне ремонтлау;

- Пушкин урамыннан Дзержинский урамындагы Яңа Шигали авылындагы күперне ремонтлау;

- Яңа Шигали авылында урам утларын ремонтлау

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»».

3. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

Звезда авыл җирлеге башлыгы: М.В.Денисова